ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
БАВЛИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАУЛЫ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

01.11.2019 ел Баулы шәһәре №305

Баулы муниципаль районы Башкарма комитетының 2017 елның 11 декабрендәге 504 номерлы карары белән расланган (2018 елның 19 июнендәге 238 номерлы карары белән кертелгән үзгәрешләр белән) Баулы муниципаль районының үзәгеннән – Баулы шәһәреннән 11 километрдан ераграк урнашкан ерак һәм аз халык яши торган авыл пунктларына кулланучылар кооперациясе оешмаларының беренче чиратта кирәкле товарларны китерүгә бәйле чыгымнарының бер өлешен каплауга Баулы муниципаль районы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибенә үзгәрешләр кертү турында

"Юридик затларга (дәүләт (муниципаль) учреждениеләрдән тыш), индивидуаль эшмәкәрләргә, шулай ук товар, эшләр житештерүче, хезмәт күрсәтүче физик затларга субсидияләр бирүне җайга салучы муниципаль хокукый актларга, муниципаль хокукый актларга гомуми таләпләргә үзгәрешләр кертү турында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2009 елның 12 сентябрендәге 1187 номерлы Карары нигезендә Баулы муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР ИТӘ:

1. Баулы муниципаль районы Башкарма комитетының 2017 елның 11 декабрендәге 504 номерлы карары белән расланган (2018 елның 19 июнендәге 238 номерлы карары белән кертелгән үзгәрешләр белән) Баулы муниципаль районының үзәгеннән – Баулы шәһәреннән 11 километрдан ераграк урнашкан ерак һәм аз халык яши торган авыл пунктларына кулланучылар кооперациясе оешмаларының беренче чиратта кирәкле товарларны китерүгә бәйле

чыгымнарының бер өлешен каплауга Баулы муниципаль районы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2.2 пунктының дүртенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«субсидия алучылар - юридик затлар үзгәртеп кору, бетерү процессында булырга тиеш түгел, аларга карата банкротлык процедурасы кертелмәгән, субсидия алучының эшчәнлеге Россия Федерациясе законнарында каралган тәртиптә туктатылмаган, ә субсидия алучылар - индивидуаль эшкуарлар эшчәнлеген индивидуаль эшкуар буларак туктатмаска тиеш;».

2. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Баулы муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең икътисади үсеш буенча урынбасарына йөкләргә.

Баулы муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе И.И. Гозәеров